ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ КАЙБИЦКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ КАЙБЫЧ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ БАШКАРМА КОМИТЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

26.02.2020 Олы Кайбыч ав. № 103

«2020 елга Татарстан Республикасы Кайбыч муниципаль районында юл хәрәкәте иминлеген арттыру» муниципаль максатчан программасына үзгәрешләр кертү турында

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Татарстан Республикасында юл хәрәкәте иминлеген арттыру, юл-транспорт һәлакәтләрен һәм алардан килгән зыянны киметү чараларын гамәлгә ашыру турында» 2019 елның 18 декабрендәге 1167 номерлы карары нигезендә, Татарстан Республикасы Кайбыч муниципаль районы Башкарма комитеты КАРАР БИРӘ:

1. Татарстан Республикасы Кайбыч муниципаль районы башкарма комитетының 2019 елның 29 декабрендәге 512 номерлы карары белән расланган «Татарстан Республикасы Кайбыч муниципаль районында 2020 елга юл хәрәкәте иминлеген арттыру» муниципаль максатчан программасына түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

«Транспорт чараларының һәм торак пунктларда җәяүлеләрнең хәрәкәтен оештыруны камилләштерүгә юнәлдерелгән оештыру-планлаштыру һәм инженерлык чаралары (млн.сум)» таблицасын 1 нче кушымта нигезендә яңа редакциядә бәян итәргә;

«2020 елга Кайбыч муниципаль районында юл хәрәкәте иминлеген арттыру» муниципаль максатчан программасын республика бюджеты, муниципаль берәмлек бюджеты һәм башка чыганаклар исәбеннән финанслау күләмнәре» бүлеген 2 нче кушымта нигезендә яңа редакциядә бәян итәргә.

2. Әлеге карарны Интернет мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә Кайбыч муниципаль районының рәсми сайтында һәм Интернет мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә «Татарстан Республикасының хокукый мәгълүматның рәсми порталы»нда урнаштырырга.

3. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны Башкарма комитет җитәкчесенең төзелеш һәм ТКХ буенча урынбасары Ф.Ш.Әхмәтовка йөкләргә.

Җитәкче А.Н.Макаров

Татарстан Республикасы
Кайбыч муниципаль районы
Башкарма комитетының
2020 елның 26.02
103 номерлы карары
1нче кушымта

## Транспорт чараларының һәм торак пунктларда җәяүлеләрнең хәрәкәтен оештыруны камилләштерүгә юнәлдерелгән оештыру-планлаштыру һәм инженерлык чаралары (млн.сум)

| № | Чара исеме | Башкару срогы | Финанслау күләме | Шул исәптән | | | Башкару өчен җаваплы | Көтелгән нәтиҗә |
|---|---|---|---|---|---|---|---|---|
| | | | | ТР бюджеты чаралары хисабына | район бюджеты чаралары хисабына | Бюджет-тан тыш чаралар | | |
| 1 | Юл билгеләрен кую, светофорлар һәм ясалма тигезсезлекләр урнаштыру | 2020 | 1,275741 | | 1,275741 | - | Кайбыч районы башкарма комитетының инфраструктура үсеше бүлеге, автомобиль юллары һәм урам челтәре балансы тотучылар, подряд оешмалары. | Җәяүлеләрне таптау, җәяүлеләрнең автомобиль юлының юл өлешенә чыгуы, тизлекне чикләүне булдырмау. |
| 2 | Торак пунктларда юлларны норматив хәлгә китерү (өслекләренең көчеш тибындагы вак таш ком кушылмасы җайланмасы, вак таш) | 2020 | 55,0 | 35,0 | 20,0 | - | «Главтатдортранс» ДКУ, Кайбыч районы башкарма комитетының инфраструктура үсеше бүлеге, автомобиль юллары һәм урам челтәре балансы тотучылар, подряд оешмалары. | Муниципаль юлларны үстерү һәм карап тору |

Татарстан Республикасы
Кайбыч муниципаль районы
Башкарма комитетының
2020 елның 26.02
103 номерлы карарына
2нче кушымта

**«2020 елга Кайбыч муниципаль районында юл хәрәкәте иминлеген арттыру» муниципаль максатчан программасын республика бюджеты, муниципаль берәмлек бюджеты һәм башка чыганаклар исәбеннән финанслау күләмнәре**

(млн. сум)

| Финанслау чыганаклары | 2020 год |
|---|---|
| Татарстан Республикасы бюджеты чаралары - барлыгы | 35,0 |
| Муниципаль юл фонды чаралары калдыгы | 1,275741 |
| муниципаль берәмлек чаралары – барлыгы | 21,331 |
| бюджеттан тыш чыганаклар – барлыгы | 0,04 |
| Программаны барлык чыганаклардан финанслау барлыгы | 57,646741 |